ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

2025 ел, 17 октябрь №8

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районына керүче Апас шәһәр җирлеге Советына Апас муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Апас шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

-предметы

1) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән административ җаваплылык каралган җирләрдән файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гражданнар тарафыннан үтәү

2) рөхсәт документларындагы таләпләрне һәм аларны үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле документлар таләпләрен контрольдә тотучы затлар тарафыннан үтәү;

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны контрольдә торучы затлар тарафыннан үтәү

булган «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле контроль орган вәкаләтләрен һәм функцияләрен.

2. Апас шәһәр җирлеге Советы тарафыннан әлеге карарның 1 Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына:

кушымтадагы форма буенча Шәһәр тибындагы Апас поселогы башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында,Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2025елга һәм 2026, 2027 еллар план чорына бюджеты турындагы карарга бюджет законнары нигезендә үзгәрешләр кертү турындагы карарның проектын эшләргә һәм тикшерүгә тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга,шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль район Башлыгы –
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Советы рәисе

А.Г. Җиһаншин

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Советының 2025 елның 17
октябрендәге 8 номерлы карарына
кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы җирлеге Башкарама комитеты вәкаләтләрен (вәкаләтләренең бер өлешен) Апас муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшыру турында килешү

штп. Апас 2025 ел, ____

Апас муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмә нигезендә эш итүче рәис Сибгатуллина Гөлнара Мөссәлим кызы йөзендә Апас муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы, алга таба «Палата», бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче җитәкче Сафина Луиза Рәвхать кызы йөзендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы, алга таба "Җирлек башкарма комитеты", икенче яктан, бергә «яклар» дип аталып, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

1. Килешү Предметы

1.1.Җирлек Башкарма комитетының Палатага түбәндәге вәкаләтләрне тапшыруы әлеге килешүнең предметы булып тора:

1) Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән административ җаваплылык каралган җирләрдән файдалану өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, гражданнар тарафыннан үтәү

2) рөхсәт документларындагы таләпләрне һәм аларны үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә кирәкле документлар таләпләрен контрольдә тотучы затлар тарафыннан үтәү;

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны контрольдә торучы затлар тарафыннан үтәү

булган «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле контроль орган вәкаләтләре һәм функцияләре.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек башкарма комитеты Палатага тапшырырга тиеш:

шушы Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары (алга таба-вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны.

2.2. Җирлек башкарма комитетының:

Палата тарафыннан вәкаләтләренең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларының шушы килешүнең 4.1 – 4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә максатчан файдаланылуын тикшереп торырга;

Палатадан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүмат алырга.

2.3. Палата:

вәкаләтләрне законнар таләпләре нигезендә гамәлгә ашырырга, шул исәптән җирлек башкарма комитеты биргән финанс чараларыннан бары тик вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен генә максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

җирлек башкарма комитетына вәкаләтләр үтәлеше турында квартал саен хисаплар, шулай ук аерым запрослар буенча килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Палатаның:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм алардан файдаланырга;

җирлек башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә өстәмә рәвештә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдаланырга.

3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен бюджет турында ел саен раслана торган карарлар нигезендә билгели (әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымталар нигезендә).

3.3. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Вәкаләтләр үтәлешен тикшереп тору

4.1. Җирлек башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, Палатадан тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүмат сорый. Палата җирлек башкарма комитеты соравы буенча сорала торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керүен тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисапларның рәвеше һәм аларны бирү тәртибе җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Тапшырылган финанс чараларының тотылуын тикшереп тору Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлегенең контроль-хисап органнары тарафыннан, шул исәптән җирлек башкарма комитеты соравы буенча да гамәлгә ашырыла.

5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1.Килешү яклар имза куйган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

5.2. Килешү, әгәр якларның берсе дә әлеге килешүнең 5.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча аны өзү турында белдермәсә, 2026 елга озайтылган дип санала.

6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

6.1. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

якларның килешүе буенча;

якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта берьяклы тәртиптә.

6.2. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә аның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча икенче якка язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс

средстволарын җирлек башкарма комитетына кире кайтара.

7. Якларның Җаваплылыгы

7.1.Әлеге килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык башлануга нигез булырга мөмкин.

8.Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

8.1.Әлеге килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә.

8.2.Бәхәсне сөйләшүләр яисә килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

10. Якларның Имзалары

| | |
|---|---|
| Апас муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе<br>___________________ Г.М. Сибгатуллина | Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты җитәкчесе<br>_________________ Л.Р. Сафина |